Мостаева, Р. Җиңүләргә алып барды татар комдивлары / Р. Мостаева // Шәһри Чаллы. – 2025. – №33 (7 май). – Б. 4.



## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 80 ЕЛЛЫГЫНА



# Җиңүләргә алып барды татар комдивлары

**Бөек Җиңү таңына халкыбызның батырлыгы һәм гаскәр башлыкларының оста җитәкчелек итә белүләре дә алып килде. Бөек Ватан сугышында 27 татар хәрби җитәкчесенең дивизияләр белән командалык итүе тарих битләрендә теркәлеп калган. Бу турыда иң төп һәм иң мөһим чыганак – Россия Оборона министрлыгының Кадрлар буенча баш идарәсе җитәкчесе генерал-полковник Виктор Петрович Горемыкин мөхәррирлегендә чыккан 5 томлы «Великая Отечественная: Комдивы» исемле хәрби-биографик сүзлектә язылган. Укчы, тау укчы, мотоукчы, моторлаштырылган һава-десант һәм кавалерия дивизияләрен яуга алып керүче милләттәшләребезнең 3-се – генерал-лейтенант, 12-се – генерал-майор, 12-се – полковник булуы әйтелә.**

Күптән түгел Чаллы журналисты Рәис Зариповның да Татарстан китап нәшриятендә «Татар комдивлары» дип аталган китабы басылып чыкты. Шушы басмада да дивизияләр белән командалык итүче 10 татар генералы турында мәгълүмат тупланган.




Автор китапны Советлар Союзы Герое – генерал-лейтенант Гани Сафиуллин турында язылган мәгълүмат белән башлап җибәрә. Сугышның беренче көннәреннән үк Сафиуллин үзен яхшы командир итеп күрсәтә. Ул һәрвакыт солдатларның гомерен саклап калу өчен тырыша. Бик күп хәрби операцияләрдә катнаша. Сталинград сугышында фашистларның иң көчле һөҗүменә аның җитәкчелегендәге 38нче укчы дивизия каршы тора. Днепр елгасын кичкәндәге батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Шулай ук укчы дивизиясе белән генерал-лейтенант Якоб Чанышев та җитәкчелек итә. Якоб Чанышевның частьләре Мәскәү, Харьков, Сталинград өчен барган сугышларда катнаша. Алар Польшаны азат итә, Одерны кичә, Берлинны камап алганда актив көрәшә.

Халык үз хәрби башлыкларын тирән хөрмәт итә һәм кадерли, алар турында җырлар иҗат ителә. 1942 елда Зәһир Исмәгыйлев тарафыннан шагыйрь Кадыйр Даян шигырьләренә язылган «Шәймуратов генерал» дип аталган җыр Бөек Ватан сугышының иң яраткан җырларының берсенә әверелә.

Генерал Миңлегали Шәймуратовның атлы сафтагы частьлары кинәт дошманга һөҗүм итеп, Гитлерның планнарын боза торган булалар. Миңлегали Шәймуратовның дивизиясе Брянск, Воронеж-Ворошиловград оборона операциясендә һәм Сталинград сугышында катнаша. Кызганычка каршы ул 1943 елда һәлак була.

Һәр сугышта разведка һәм контрразведка да зур роль уйный. «Серле сугыш» («Тайная война») кырларында сугышкан хәрби разведка җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре рәтендә Татарстаннан якташларыбыз аз түгел. Алар арасында татар милләтеннән булган 7 хәрби җитәкче билгеле. Шуларның берсе – ике дистә ел гомерен хәрби разведкага багышлаган бригада командиры Минзакир Әпсәләмов бар. Ул көньяк-көнбатыш юнәлешендә барган сугышларда партизан хәрәкәтен оештыра. Ленинградны, Карелияне азат итүдә катнаша, Фин һәм Норвегия чигенә кадәр барып җитә, күп кенә хәрби орденнар белән бүләкләнә.

Кыскасы, милләттәшләребез сугышның барлык почмакларында да үзләрен оста җитәкче итеп таныталар: 6нчы моторлаштырылган һава-десант корпусын оештырган генерал-майор Александр Кирзимовның, Севастополь оборонасында катнашкан генерал-майор Пётр Новиковның, 29нчы моторлаштырылган дивизиясе белән командалык иткән генерал-майор Ибраһим Бикҗановның сугышчылары Бөек Ватан сугышында чын батырлык үрнәкләре күрсәтәләр.

Якташыбыз Рәис Зариповның хәрби өлкәдә зур уңышларга ирешкән милләт улларының язмышларына багышлап язылган «Татар комдивлары» китабы беркемне дә битараф калдырмас. Бу тема белән кызыксынган һәркемне шәһәрдәшләребезнең Үзәк китапханәсендә көтеп калабыз.

Розалия Мостаева, Шәһәр үзәк китапханәсе китапханәчесе